**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУГАРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422662, с.Кугарчино,
ул. Совентская, дом 62А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘРЧЕН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422662,Күгәрчен авылы
Советская урамы, 62А нчы йорт,

Тел.: (84361) 28589, факс: (84361) 28589, e-mail:Kugar.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

КАРАР № 43

19.09.2018 Күгәрчен авылы

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Күгәрчен авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы белән карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Советы белән берлектә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә.:
«2018 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, үзара салым кертү белән килешәсезме?:

-Күгәрчен авылында Гагарин, Чкалов , Зәңгәр Күл авылында Тукай урамнарындагы юлларга вак таш сатып алу һәм ремонт ясау;
- Күгәрчен авылында каты көнкүреш калдыклары җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру.;
- Күгәрчен һәм Зәңгәр Күл авыллары торак пунктларында юлларны кышкы чорда карап тоту ;

- Күгәрчен авылында су торбаларын ремонтлау;
- Күгәрчен авылында эчә торган су алу өчен насос сатып алу.

«ЮК» « ӘЙЕ».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күгәрчен авылы, Совет урамы, 62А, Зәңгәр Күл авылы, Тукай урамы, 3А адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru күрсәтергә

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлы А.Т.Сафин